БАЛТАСИНСКИЙ
РАЙОННЫЙ СОВЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ РАЙОН СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

5 сентябрь 2023 ел № 207

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы «Сосна авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең генераль планын раслау турында**

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Сосна авыл җирлеге территориясенең шәһәр төзелешен планлаштыруны гамәлгә ашыру максатларында,Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 24 статьясына,«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14,15статьяларына,Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Уставына таянып, гавами тыңлаулар һәм килештерү комиссиясе нәтиҗәләре буенча,Татарстан Республикасы Балтач район Советы **карар бирде:**

1.Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы «Сосна авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең генераль планын 1 нче, 2 нче кушымталар нигезендә расларга.

2.Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Сосна авыл җирлеге башкарма комитетына:

- әлеге карарның 1 пункты белән расланган генераль план нигезендә шәһәр төзелеше эшчәнлеген гамәлгә ашырырга;
- Сосна авыл җирлегенең торак пунктлары чикләрен күчемсез милекнең бердәм дәүләт реестрына кертергә;
- Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы «Сосна авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең генераль планын раслау турындагы карарны Территориаль планлаштыруның федераль дәүләт мәгълүмат системасына урнаштыруны тәэмин итәргә.

3.Әлеге карарны Балтач муниципаль районының baltasi.tatarstan.ru рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

Балтач муниципаль районы
башлыгы урынбасары
Балтач район Советы рәисе урынбасары Н.Н. Сабирҗанов